



# *I бүлек*

**Борынгы татарларда кием -салым**






Белгән кеше бар микән: бу татар мөселманнарның киеменең формасы кай заманадан бирле калган икән? Татарда бар кием: күлмәк, ыштан, камзул, казаки, җилән, чапан һ.б. Бу киемнәрнең бәгъзесе бар, башка халыкта һичберәүдә күренми. Һичбер халыкның киеменә охшамый. Бу якын тирәдәге халыкларда ирләр күлмәге күбрәк озынлыгы тезгә җитәр-җитмәс буладыр, җиңел ситсадан яки бүздән, һәркем үзенең теләгәненә күрә.



Иң астан кия торган киемдер, күлмәк өстеннән, урысларның жилеты урынына. Якалы була, алдан төймәлиләр биш я алты төймә белән һәм кесәләре була. Ул камзулның тагы бер төрлесе була кыска җиңле, җиңе терсәгенә җитәр-җитмәс. Ул камзул күп кешедә әдрәстән я бикасаптан була.

Дәхи казаки дигән кием попларның полукафтаны кебегрәк була; озын була, тездән була, тездән түбән, тубыкка чаклы, һәртөрле нәрсәдән. Элгәре күбрәк әдрәстән, бикасаптан буладыр инде.



Ул кәләпүш асыл Бохардан, сартлардан чыккан нәрсә. Ул кәләпүш фарсыча сүз: кәлә-баш мәгънәсендә, пүш-япмак мәгънәсендә; баш капкачы дигән кебек була. Ул кәләпүшне башка бертөрле ефәк материядән, хәтфәдән ясыйлар әйләнәсенә ука тотып. Ефәк чуклы була түбәсендә. Аны һәм яхшы итеп эшлиләр, ул кәләпүшне әдрәстән, бикасаптан, ситсадан вә һәртөрле материядән.



Чалбар кияләр.. Махсус татар чалбары була,урыс чалбарына башкарак; төбе бик киң була, балак очлары таррак; бу чалбарны балагын чыгарып йөреп булмый. Балакны чыгарып йөри күп кешеләр. Һәртөрле халыкта булса кирәк, хатын-кыз киеме белән ирләр киеме бер төрле түгел. Ирләр киеме белән хатыннар киеме арасында күп аерма бар. Инде хатын-кыз киемнәре менә: күлмәк, ыштан, читек, башмак, кәвеш, камзул, тун, яулык, шәл.



Хатыннар күлмәге бик озын була, җиргә чаклы, аякны капларлык; шәригать буенча хатыннар киеме шулай кирәк. Хатыннар күлмәгенең итәге ике кат була. Элгәре күлмәкнең итәге башка төстән була торган иде, инде күлмәге белән бер төсле була. Ситса була, унике аршын яки унөч аршын ситса кирәк.

